ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“14” октябрь 2020 ел Сәмәкәй авылы №10

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Сәмәкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23.1 ст. нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылында 2020 елның 24 октяберендә 11.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылы территориясендә 2020 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенен Күгәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Урман урамы буенча юл ремонтлау;
- тукталышта борылыш мәйданчыгын ремонтлау;

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күгәш авылы, Урман урамы, 30 нчы йорт адресы буенча гражданнар жыенын үткәрергә.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы
Совет Рәисе И. М. Усманов